ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» июня 2019 г. № 221

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Тәбәрле башлангыч мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында белем бирү учреждениеләренең оптималь челтәрен булдыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2019 елның 30 маенда кабул ителгән “Тәбәрле башлангыч мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен үзгәртеп кору турында Карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү нигезендә һәм Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 57-59 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Тәбәрле башлангыч мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Омга лицее”на кушу юлы белән үзгәртеп корырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Тәбәрле башлангыч мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Д.С.Гәрәевага:

- гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль бюджет учреждениесен үзгәртеп оештыру белән бәйле чаралар үткәрергә;
- тапшыру актын 2019 елның 1 августына кадәр раслауга әзерләргә;
- гамәлдәге законнар нигезендә үзгәртеп кору процедурасының башлануы турында ТР буенча 18 нче Федераль салым хезмәтенең районара инспекциясенә хәбәр итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Сарсак-Омга лицее” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры С.Ю.Маркитоновка:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Тәбәрле башлангыч мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучыларының шәхси эшләрен кабул итеп алырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р.Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.С. Авдеев**